КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 март г.Казань № 284

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 931 нче карары белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарга үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 931 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 25 ноябрь, 1124 нче; 2021 ел, 24 декабрь, 1277 нче; 2021 ел, 24 декабрь, 1284 нче; 2022 ел, 15 гыйнвар, 19 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.3. | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе | гамәли фәнни тикшеренүләр үткәрү | 197 572 052,0 |
| | | фундаменталь фәнни тикшеренүләр үткәрү | 89 226 088,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | мәдәни мирас объект-ларын саклап калуны һәм алардан файдала-нуны тәэмин итү | 18 482 546,8 |
| | | мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат базала-рын алып бару | 5 735 962,8 |
| | | фәнни-методик тәэмин итү | 7 647 950,4»; |

3.2 пунктның 4 графасында «12 093 000,0» саннарын «13 593 000,0» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин